КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 август г.Казань № 622

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче, 2021 ел, 31 август, 788 нче, 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче, 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче, 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы, 2022 ел, 15 март, 240 нчы, 2022 ел, 22 июль, 707 нче, 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы, 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы, 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы, 2023 ел, 21 февраль, 168 нче, 2023 ел, 4 июль, 786 нчы, 2023 ел, 9 август, 961 нче, 2023 ел, 5 октябрь, 1239 нчы, 2024 ел, 4 март, 119 нчы, 2024 ел, 17 апрель, 258 нче, 2024 ел, 10 май, 317 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән элиталы орлыкчылыкка ярдәм итүгә һәм (яисә) орлыклар сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Субсидия алучылар тарафыннан игълан ителгән субсидия бирүгә ихтыяҗның гомуми күләме әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең китерелгән лимитлары күләменнән артып киткән очракта, субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия суммасы түбәндәге формулалар буенча Министрлык тарафыннан билгеләнә:http://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=RLAW363&n=177890&dst=100027&field=134&date=24.06.2024

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә ($W_{кэс}$):

$$W_{кэс} = W_{эс} \times K,$$

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендәhttp://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=RLAW363&n=177890&dst=102399&field=134&date=24.06.2024 ($W_{кс}$):

$$W_{кс} = W_{с} \times K,$$

монда:

К - түбәндәге формула буенча билгеләнә торган төзәтү коэффициенты:

$$K = \frac{V}{\left(\sum_{i=1}^{n} W_{эс\ (i)} + \sum_{i=1}^{h} W_{с\ (i)}\right)} \leq 1,$$

монда:

V - әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең китерелгән лимитлары күләме;

n – әлеге Тәртипнең 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә субсидия алучылар саны;

h – бу Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә субсидия алучылар саны.»;

әлеге карар белән расланган Бөртекле, кузаклы ашлык, майлы (рапс һәм соядан тыш), азык авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенең 25 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле йөкләмәләрен үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы сайлап алуда катнашучыларның өчен салым салуның кулланыла торган системасы турында салым органыннан белешмә кәгазе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин